ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

---

**18 нче март 2019ел** **№ 49**

# КАРАР

**Арча муниципаль районы «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында»гы проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 8, 31-33 маддәләре, 2010 елның 25 декабрендәге 98-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Сеҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Арча муниципаль районы «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында»гы проектын әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук түбәндәге адреслар буенча Сеҗе авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда, кеше күп җыела торган урыннарда урнаштырырга: Курса Почмак авылы,Мәктәп урамы,1нче йорт,Сикертән авылы,Үзәк урам,14нче йорт,Сеҗе авылы,Мәктәп урамы,25 йорт.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл
җирлеге башлыгы Гибадуллина Г.М.